Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

«10» март, 2022 ел № 4

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2021 елның 27 октябрендәге 115 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Шигалеев авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында»

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге уставы белән, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2022 елның 10 мартындагы 230 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2021 елның 27 октябрендәге 115 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Шигали авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге башлыгы В.М. Сәлимов